# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Урта Тигәнәле авылы

16 ноябрь 2020 ел. № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Урта Тигәнәле авыл җирлеге составына керүче Урта Тигәнәле торак пунктында гражданнар җыены

**Карар итте**:

1. 2021 елда Урта Тигәнәле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларына чакырылган гражданнардан тыш, 1500 сум күләмендә үзара салым кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге чараларга юнәлдерергә:

- авыл эчендәге юлларны төзекләндерү
- җирләү урыннарын төзекләндерү
- кышкы һәм җәйге чорда юлларны карап тоту
- су башнясын алыштыру
- урам тренажерлары сатып алу, баскетбол мәйданчыгы җиһазларын урнаштыру;
- күлне төбен чистарту белән төзекләндерү
- су белән тәэмин итү трассасын ремонтлау һәм салу
- Тиганка елгасы аша күпер һәм җәяүлеләр кичүе төзелеше

3. Әлеге карарны Урта Тигәнәле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Урта Тигәнәле авыл җирлеге Урта Тигәнәле мәдәният йортында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Урта Тигәнәле авыл җирлеге башлыгы И.К.Хаматвалиев

СОВЕТ СРЕДНЕТИГАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ